**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының**
**Яңа Кади авыл җирлеге гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

**№1** **22.10.2021 ел**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге составына керүче Утыз Имән һәм Кызыл Чишмә авылы торак пунктларында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 22 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2022 елда Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

-Утыз Имән торак пунктында "Чәчәкле алан" чишмәсе территориясен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алуга;

- Утыз Имән һәм Кызыл Чишмә торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;

- МТЗ-82 тракторы өчен 2 ПТС -4 трактор арбасы сатып алу.

- Утыз Имән торак пунктында Совет урамында, 200 метр Пионерская урамында урам-юл челтәрен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу: (20-30 мм фракциясендә вак таш сатып алу)

«РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 340 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 174 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 173 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен 1 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге составына керүче Утыз Имән авылы торак пунктында халык җыены **булып узган**, халык җыены нәтиҗәләре - **чын** дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2022 елда Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

-Утыз Имән торак пунктында "Чәчәкле алан" чишмәсе территориясен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алуга;

- Утыз Имән һәм Кызыл Чишмә торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;

- МТЗ-82 тракторы өчен 2 ПТС -4 трактор арбасы сатып алу.

- Утыз Имән торак пунктында Совет урамында, 200 метр Пионерская урамында урам-юл челтәрен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу: (20-30 мм фракциясендә вак таш сатып алу) -

**кабул ителгән дип танырга.**

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: Утыз Имән авылы, Совет урамы, 51нче йорт. Чирмешән муниципаль районының рәсми интернет-сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче**
**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Яңа Кади авыл җирлеге башлыгы** **М.М.Әминов**